Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.02.2021 Менделеевск ш. № 88

Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын формалаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең уртак коллегиясе Беркетмәсен гамәлгә ашыру максатында 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 апрелендәге 276 нчы номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын формалаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Административ регламентның 2 бүлегенең 2.6 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге эчтәлекле 2 пункт белән тулыландырырга:

«2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр – Россия ФСХ.».

1.2 Административ регламентның 2 бүлегенең 2.8 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булуы.».

1.3. Административ регламентның 3 бүлегенең 3.4 пунктындагы 3.4.1 пунктчасын

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә түбәндәгеләр турында соратулар җибәрә:

1) күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр бирү (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүмат булган).

2) Салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычларның барлыгы (булмавы) турында белешмәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.
Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорату.»

2. Әлеге карарны hh//pravo.tatarstan.ru/ рәсми порталында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы С.В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.А. Абдуллин